ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 471-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 471-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2112-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## «Оешмалар мөлкәтенә салым турында»Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «башкача каралмаган булса» сүзләре алдыннан «һәм Россия Федерациясе Салым кодексы белән» сүзләрен өстәргә;

2) $2^1$ өлештә «2023» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлыы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнгән.

Федераль закон белән гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга карата оешмалар мөлкәтенә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән салым буенча 1,6 проценттан артмаган салым ставкаларының гамәлдә булу вакытын 2024-2026 елларга озайту билгеләнде. Татарстан Республикасы территориясендә әлеге түбәнәйтелгән ставка 2020 елдан гамәлдә. Закон проекты салым түләүчеләрнең югарыда күрсәтелгән категориясе өчен 1,6 процент күләмендәге салым ставкасын 2024-2026 елларга  озайтуны тәкъдим итә.

Закон проекты Татарстан Республикасы законнарын Россия Федерациясе Салым кодексы нормаларына туры китерүгә юнәлдерелгән.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетына салым преференцияләреннән гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булган, суммасы елына якынча 172 млн.сум дип бәяләнә торган корылмаларга карата керемнәр кермәүгә китерәчәк.